**Рәзинә ХӘСӘНОВА**

# ЗУР ӘДӘБИЯТКӘ КИТЕРГӘН ЮЛ

Кеше гомеренең һәр мизгеле кабатланмас булса да, аның Балачак дигән могҗизалы һәм иң кадерле чоры бар. Ул һәркайсыбызның күңелендә аерым урын били, онытылмас хатирәләре белән кереп урнаша. Ә кайбер вакыйгаларның исә кешенең киләчәк тормыш юлын билгеләве дә бар. Мәсәлән, мәктәп елларында әдәби берләшмәдә шөгыльләнү Чаллы дәүләт педагогия институтының татар филологиясе кафедрасы мөдире әдәбиятчы һәм текстолог, филология фәннәре докторы, ТР Язучылар берлеге әгъзасы Әнвәр Шәрипов өчен әдәбият дөньясына юл ача.

Әнвәр Мәгьдәнур улының әнисе ягыннан нәсел тамырлары Лениногорск районының тау итәгендә яшеллеккә күмелеп утырган Зәй Каратай авылына барып тоташа. Әтиләре үлгәннән соң, 1952 елда, алар бирегә күченәләр. Балачагы, яшьлек еллары узган якны Әнвәр Мәгъдәнурович үзенең туган ягы дип саный. Әнвәр Шәрипов хатирәләрендә авылның иң күркәм урыны булган Шәрифҗан бабайның яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы саклана «Тау итәгендә утырган бу урын оҗмах почмагын хәтерләтә иде: бабайның утыртмаган бер җимеше дә калмагандыр, мөгаен. Без анда экскурсиягә йөри идек», – дип искә ала ул.

Булачак галимнең әдәбиятка һәм тел гыйлеменә тартылуы шушы гүзәл табигатьле җирдә ачыла. 8нче сыйныфта укыганда ул Лениногорскига йөреп, «Ильич васыятьләре» газетасы каршында эшләп килүче «Чишмә» әдәби берләшмәсендә каләм тибрәтә башлый. «Каты токым», «Тирән катлам» романнары авторы Шамил Бикчурин җитәкчелегендә шөгыльләнү үсмердә матур әдәбиятка мәхәббәтне тагын да ныгыта. «Безнең авыл шәһәрдән 21 чакрым ераклыкта урнашкан. Берләшмәнең эше исә кичке биштә башланып, сигезләрдә генә тәмамлана. «попутка»да кайта торган түгел. Бу очрашулар шулкадәр ошый иде ки, хәтта соңга калганда үземә кунарга фатир да таптым. Икенче көнне иртүк торып, мәктәпкә кайтып җитә идем. Шамил абыйнын, дәресләре бик җанлы ә үзе – безгә, иҗатка тартылган балаларга, җитди мөнәсәбәте белән истә калган. Аеруча мин аңа проза жанрында язуның серләренә тешендерүе өчен рәхмәтлемен», – ди Әнвәр Мәгъдәнур улы.

Иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнү, әдәби әсәрләр тудыруның нигезләренә Лениногорскидагы әдәби берләшмәдә төшенә башлаган Әнвәр Шәрипов бүгенге көндә борынгы төрки әдәбияты белгече буларак билгеле. Аның төрки-татар әдәбияты проблемаларын тарихи планда өйрәнеп язылган хезмәтләре бихисап. Бәлки шуларны күздә тотыптыр, якташы Җәмит Рәхимов «Батырша» романын әзерләгәндә аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Шулай итеп, тарихи романга тел галименең дә берникадәр өлеше керә.